**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Мәлбагыш авыл җирлеге Советы карары**

Мәлбагыш авылы №50 17 март 2017 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымы турында һәм гражданнарның үзара салым акчаларын җыю һәм куллану тәртибе хакында 2014 елның 08 маендагы 92-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 56 статьясы нигезендә

Мәлбагыш авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымы турында һәм гражданнарның үзара салым акчаларын җыю һәм куллану тәртибе хакында 2014 елның 08 маендагы 92-1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 3.1 пунктта «агымда» сүзләрен «агымда» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 4.2 пунктта «саны Җирлектә яшәүчеләрнең гомуми санының 30 процентыннан арта алмый торган һәм алар өчен түләүләр күләме киметелергә мөмкин булган. Күрсәтелгән категориядәге гражданнар җирле референдумда кабул ителгән карар белән билгеләнә.» сүзләрен өстәргә;

1.3. 5.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү җирле референдумда кабул ителгән тиешле карар халыкка җиткерелгәннән соң ике ай эчендә Җирлек Башкарма комитетының банк реквизитларын үз эченә алган хәбәр итү нигезендә, шулай ук түләү тәртибе турындагы мәгълүмат нигезендә башкарыла. "

2. Әлеге карарны веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo. tatarstan.ru. һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча урнаштырырга: http//aznakayevo. tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Мәлбагыш авыл җирлегенең законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис: И.Ә.Әхтәмова